КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 декабрь г.Казань № 1129

Спортның олимпиягә кермәгән төрләре буенча спорт әзерлеге дәүләт хезмәтенең сыйфаты стандартын раслау турында

Дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын күтәрү, халыкның барлык категорияләренә дә аннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешмаларга таләпләрне стандартлаштыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Кararга теркәлгән Спортның олимпиягә кермәгән төрләре буенча спорт әзерлеге дәүләт хезмәтенең сыйфаты стандартын расларга.
2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына әлеге карар белән расланган Спортның олимпиягә кермәгән төрләре буенча спорт әзерлеге дәүләт хезмәтенең сыйфаты стандартын муниципаль учреждениеләр күрсәтә торган тиешле муниципаль хезмәт күрсәтүләр сыйфатын бәяләү өчен кулланырга тәкъдим итәргә.
3. Бу карар 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.
4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин